**_Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы_**
**Бирючевка авыл җирлеге Советы**
**Карары**

Бирючевка авылы № 7 01 июнь 2021 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Бирючевка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты хакында

Җирле үзидарә турында федераль һәм республика законнарына үзгәрешләр кертү белән бәйле

Бирючевка авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Бирючевка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Бирючевка авыл җирлеге Советы карары проектын кабул итәргә (1 нче кушымта). 2. Әлеге карарны, 2021 елның 5 июньгэ кадэр соңга калмыйча, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http:// aznakyevo.tatarstan.ru, Бирючевка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

3. 2021 елның 2 июль 17.00 сәгатьтә, Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы,Бирючевка_авылы, Школьная урамы, 2 йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Бирючевка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча ачык тыңлаулар уздырырга.

4. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Бирючевка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча тәкъдимнәр

һәм искәрмәләр, ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча бирелергә мөмкин:_Бирючевка авылы, Школьная урамы, 2йорт.

5. Халык тыңлауларын үткәрү буенча эшче төркем төзергә

- Крашенинников В.В - Бирючевка авыл җирлеге башлыгы;

- Большаков А.И - Бирючевка авыл җирлеге депутаты;

- Нуреева М.Г- Бирючевка авыл җирлеге депутаты.

6. Ачык тыңлаулар үткәрү буенча эшче төркемгә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Бирючевка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрүне, гражданнарны кабул итү, исәпкә алуны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

7. Законлылык һәм хокук тәртибе мәсьәләләре буенча даими комиссия халык алдында әйтелгән һәм фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып карар проектын эшләп бетерергә һәм чираттагы утырыш каравына кертергә тиеш.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Крашенинников В.В

Татарстан Республикасы
Азнакай муниципаль районы
Бирючевка авыл җирлеге Советы
карарына 1 нче кушымта
«01» июнь 2021 № 7

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Бирючевка авыл җирлеге Советының 2012 елның 23 гыйнварындагы 30 номерлы карары белән расланган (24.09.2012 №45, 05.08.2013 №65, 22.10.2014 №100, 30.09.2015 №8, _15.11.2016 №43_, 17.04.2018 №92,03.09.2018 №103, 05.11.2019 №151, 17.11.2020 №183_карарлар редакциясендә), Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы "Бирючевка авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертерегә:

1.1. 7 статьяның 1 өлешен түбәндәге эчтәлекле 17 пунктча өстәргә:
«17) алкоголь, наркотик яки башка токсик исерек хәлдә булган затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру.».

1.2. 47 статьяның 1 өлешендәге 7 пунктчасын түбәндәге эчтәлекле сигезенче абзац өстәргә:
« - алкогольле, наркотик яки башка токсик исерек хәлдә булган затларга ярдәм күрсәтү чараларын гамәлгә ашыра.».

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.

3. Дәүләт теркәвенә алынганнан соң әлеге карарны “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча: http:// aznakyevo.tatarstan.ru., Бирючевка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.